Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 19 нчы ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, ялгыз өлкән пенсионерлардан һәм балигъ булмаган балалар тәрбияләүче гаиләләрдән,Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор авылында яшәү урыны буенча теркәлгән , балигъ булган һәр гражданга 2023 нче елда үзара салымны 1600 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
- Ю. Гагарин һәм М.Җәлил урамнары буенча вак таш җәю;
- Ю.Гагарин урамы буенча асфальт җәю;
- Чишмәгә илтүче юлларны төзекләндерү;
-Ю.Гагарин урамы буенча су белән тәэмин итүче ике трассаны берләштерү эшләрен тәгалләү;
-Ор авылы зиратының коймаларын буяу өчен буяу материаллары сатып алу.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Х.Салихҗанов